**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 58
факс: 8 (84346) 2-17-57

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.58
тел: 8 (84346) 2-10-48

48№ 2014 елның 23 ноябре

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

«Иң яхшы Яңа ел чыршысы» һәм «Боз сыннарын иң яхшы башкаручы» исеменә конкурс уздыру турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре үткәрелү уңаеннан, шулай ук Яңа ел бәйрәмнәре чорында район территориясенең эстетик төрен арттыру максатларында Әлки муниципаль районы Башлыгы карар бирә:

1. «Иң яхшы Яңа ел чыршысы» һәм «Боз сыннарын иң яхшы башкаручы» исеменә район конкурсын игълан итәргә.
2. Конкурсны уздыру турындагы нигезләмәне һәм конкурс комиссиясе составын (1, 2 нче кушымталар) расларга.
3. Әлеге карарны «Әлки хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары М.А. Платоновага йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башлыгы Ф.М. Дәүләтшин

Баш. Гарипова Р.М.
Тел. 8(84346)20-0-51

Әлки муниципаль районы
Башлыгының 2014 елның
____________ ____номерлы
карарына 1 нче кушымта

**“Иң яхшы Яңа ел чыршысы”, "Боз сыннарын иң яхшы башкаручы" исеменә конкурс турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

**1.1.** “Иң яхшы Яңа ел чыршысы” һәм “Боз сыннарын иң яхшы башкаручы” исеменә конкурс (алга таба - конкурс) Әлки муниципаль районы территориясендә 2014 елның 1-20 декабрендә үткәрелә.

## 2. Конкурсның максатлары

2.1. Конкурс физик һәм юридик затларның активлыгын күтәреп Әлки муниципаль районы халкы һәм кунаклары өчен бәйрәм атмосферасы булдыру, шулай ук район территориясендә яңа ел бәйрәмнәре чорында матурлыкны арттыру максатларында уздырыла.

## 3. Конкурс үткәрү һәм җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

3.1. Конкурста Әлки муниципаль районы территориясендә теркәлгән барлык милек рәвешләрендәге оешмалар, физик һәм юридик затлар катнаша.

3.2. Конкурс конкурс комиссиясе билгеләгән бәйрәм чыршыларын тикшерү юлы белән уздырыла.

3.3. Конкурста җиңүче дип таныла:

3.3.1. иң яхшы Яңа ел чыршысы түбәндәге нигезләрдә:
- матур һәм зәвыклы бизәү;
- чыршыда янучы утлар булу;
- өстәмә яңа ел бәйрәм атрибутлары булу;

3.3.2.Боз фигураларын түбәндәге нигезләрдә иң яхшы башкару:
- теманы ачу тирәнлеге;
- сәнгатьчә тәэсирлелек;

башкару катлаулылыгы;
- Материалны эшкәртү чисталыгы.

3.4. Комиссия 2014 елның 20 декабренә йомгак ясый.

## 4. Бүләкләү

4.1. Конкурста җиңүчеләр беренче, икенче һәм өченче дәрәҗә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнәләр.

4.2. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшыру Әлки муниципаль районы Башлыгы киңәшмәсендә 2014 елның 29 декабрендә үткәрелә.

4.3. Конкурс нәтиҗәләре “Әлки хәбәрләре” газетасында басылып чыга һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 елның 23 июлендәге 277 номерлы карарына 1 нче кушымта

Әлки муниципаль районы
Башлыгының 2014 елның
____________ ____номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Конкурс комиссиясе составы**

Платонова
Мария Андреевна Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе ( килешү буенча)

**Комиссия әгъзалары:**

Гайфуллина
Рәсимә Әхәт кызы "Әлки мәдәният бүлеге" МКУ начальнигы ( килешү буенча)

Шишкина
Наиля Исмаиловна Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы ( килешү буенча)

Низамиев
Азат Рөстәм улы "Әлки хәбәрләре"газеты мөхәррире ( килешү буенча)

Камалов
Рәмис Әнвәр улы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге белгече ( килешү буенча)